ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.03.2021

Иннополис шәһәре

КАРАР
№58

Массакүләм спорт һәм гавами чаралар уздыру вакытында гомуми файдаланудагы юлларны вакытлыча ябу турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә TIMERMAN сериясенең «Иннополумарафон - 2021» җиңел атлетика ярышлары вакытында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021нче елның 10нчы апрелендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә TIMERMAN сериясенең «Иннополумарафон - 2021» (алга таба – Ярышлар) сериясе җиңел атлетика ярышлары вакытында 13.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатып торуны тәэмин итергә.

1.2. Транспорт чаралары Университет урамы буенча Квант бульвары белән кисешкән урынга кадәр, Үзәк урамы буенча «ЗИОН» торак-коммуналь комплексына керү юлы белән киселешкә кадәр, шулай ук Үзәк урам буенча «Иннополис» медицина үзәгенә кадәр хәрәкәт итәчәк. Әлеге участокларда ревсив хәрәкәт оештырылачак

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенә тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1нче пункты нигезендә Иннополис шәһәрендә Ярышлар үткәрүне тәэмин итү өчен барлык төр транспорт чаралары хәрәкәтен туктатуны оештырырга;

- Ярышларда катнашучылар һәм тамашачылар иминлеген тәэмин итү, аны уздыру чорында транспорт хәрәкәтен җайга салу буенча кирәкле чаралар күрергә;

- Ярышлар уздырыла торган урыннарга якын урамнардагы оператив хәлләрне исәпкә алып, транспорт хәрәкәтен чикләү, яки ябу буенча карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2021нче елның 12нче мартыннан 58нче номерлы карарына кушымта

